## БЕЗНЕҢ ӘТИ!

Өйдә зур хөрмәткә лаек,
Гел өстен калган сүзе,
Кырыс булып тоелса да,
Сабый баладай үзе.

*Кушымта:*
Кем дисезме? Кем дисезме?
Әни дисездер бәлки?
Әни өчен дә кадерле
Ул безнең шундый әти.

Гаиләсе янда булганда
Нур чәчеп торган күзе,
Ни генә була калса да,
Һәрвакыт сабыр, түзем.